ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирин Батыршин, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 18** **04.12.2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының
Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетының 2023
елның 25 июлендәге 11 санлы карары белән расланган
Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә беренчел
хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, 1996 елның 31 маендагы «Оборона турында»гы 61-ФЗ санлы Федераль закон, 1997 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында»гы 31-ФЗ санлы, 1998 елның 28 мартындагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»гы 53-ФЗ санлы, 2023 елның 14 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы санлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында»гы 719 санлы карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә һәм җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты

К А Р А Р Б И Р Ә:

1. Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 1.Нигезләмәнең 1.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Түбәндәге гражданнар хәрби исәпкә алынмый:

а) «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон нигезендә хәрби бурычларны үтәүдән азат ителгәннәр;

б) хәрби хезмәт узучылар яисә альтернатив граждан хезмәте узучылар;

в) хәрби-исәп белгечлеге булмаган хатын-кызлар;

г) Россия Федерациясеннән читтә даими яшәүче;

д) офицерларның хәрби исемнәре һәм Россия Федерациясенең тышкы разведка хезмәте һәм Россия Федерациясенең Федераль иминлек хезмәте запасында булучылар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев